**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Четырчы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

23 гыйнвар 2019 ел №63/1

Четырчы авыл җирлеге Советының
04.06.2014 елда кабул ителгән
”Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Четырчы
авыл җирлеге территориясендә
гражданнарга үзара салым салу һәм гражданнардан
үзара салым акчасын җыю һәм файдалану тәртибен
раслау турында”гы 6/1 нче карарына
үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче Федераль законы, ”Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Четырчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Четырчы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Четырчы авыл җирлеге Советының 04.06.2014 елда кабул ителгән ”Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Четырчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым салу һәм гражданнардан үзара салым акчасын җыю һәм файдалану тәртибен раслау турында”гы 6/1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“Гражданнарга үзара салым салу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены - гамәлдәге закон, җирлек составына керүче торак пунктларында аның территориясендә даими яки өстенлекле яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр арасында гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турындагы Нигезләмә

нигезендә гражданнарга үзара салым салу мәсьәләсе буенча үткәрелүче гражданнар җыены”;

2 бүлек исемендә “референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

2.1нче пунктында “референдумда” сүзеннән соң “(гражданнар җыенында”) сүзләрен өстәргә”;

түбәндәге эчтәлектәге 2.3нче пунктны өстәргә:

“2.3. Торак пунктта гражданнарга үзара салым салу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү инициативасы түбәндәгеләргә карый:

- авыл җирлеге башлыгы;

- сайлау хокукы булган, гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган, 10 кешедән ким булмаган торак пунктта яшәүчеләр төркеме, (ягъни Россия Федерациясенең хокукка сәләтле, торак пункт территориясендә даими яки өстенлекле яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән гражданнары), шулай ук торак пункт территориясендә даими яки өстенлекле яшәүче һәм Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне тормышка ашырганда хокукка ия булган чит илләр гражданнары.”;

3нче бүлек исемендә “референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

3.1 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“ Инициатива төркеме белән чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә, ә җирлек башлыгы инициативасы буенча барлык кирәкле документлар (гражданнар җыены алар нигезендә билгеләнә) кереп беткәннән соң 30 көн дәвамында.”;

3.2 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“ Гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү тәртибе Җирлек Уставы тарафыннан билгеләнә.”;

3.3.нче пунктта “референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

4нче бүлек исемендә “референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

4.1нче пунктта “референдумда” сүзеннән соң “(гражданнар җыенында”) сүзләрен өстәргә”;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.2. Референдум (гражданнар җыены) үзара салым салу буенча түләү күләмнәрен һәм җирле билгеләнештәге төгәл мәсьәләләрне раслый, җыелган акча әлеге мәсьәләләрне хәл итүгә тотыла. Түләүләр күләме гражданнарның үзара салымы тәртибендә Җирлекнең (торак пунктның) барлык гражданнары өчен дә абсолют тигез күләмдә билгеләнә, гражданнарның аерым категорияләреннән кала, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин.”;

4.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.3. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карар Җирлекнең мәгълүмат стендларында, яшәүчеләр

күпләп җыела торган урыннарда урнаштыру юлы белән халыкка белдерелергә тиеш. Җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карар рәсми халыкка белдерелгән көннән үз көченә керә.”;

4.4. нче пунктта:

“референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

“Җирлек” сүзеннән соң “(торак пункт”) сүзен өстәргә.”

5нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Үзара салым акчасын җыю тәртибе

5.1. Үзара салым акчасын җыю тәртибе референдум (гражданнар җыены) карарын үтәү йөзеннән кабул ителгән Җирлекнең башкарма комитет карары белән билгеләнә һәм рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка белдерелергә) тиеш.”;

6.1. нче пунктта:

“Әлеге Нигезләмәнең 5.1 нче пункты нигезендә” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

“референдумда” сүзеннән соң “(гражданнар җыенында”) сүзләрен өстәргә”;

6.2. нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.2. Җирлекнең башкарма комитеты референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карар үз көченә кергәннән соң 15 көн эчендә үзара салым акчасын җыю Тәртибен әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын билгели.”;

6.3нче пунктта “референдум” сүзеннән соң “(гражданнар җыены”) сүзләрен өстәргә”;

6.4 нче пунктта “референдумда” сүзеннән соң “(гражданнар җыенында”) сүзләрен өстәргә”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка белдерергә, шулай ук Чистай муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аны халыкка рәсми белдергәннән соң үз көченә керә.

Четырчы авыл
җирлеге башлыгы М.В.Новиков